Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы

КАРАР №7

«19» декабрь 2025 г Югары Сәрдә авылы

Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы 11.11.2019 ел 110 номерлы карары белән расланган «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр керту хакында

2025 елның 21 апрелендәге №84-ФЗ Федераль законына («Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законның 14 һәм 15 нче статьяларына үзгәрешләр керту турында») һәм 12.12.2025 елдагы № 020802-2025/Прдп359-25 номерлы Әтнә районы прокуратурасының протесты буенча, Әтнә муниципаль районының Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы, 11.11.2019 ел, № 110 номерлы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы карары белән расланган (10.02.2020 ел, №122; 28.05.2020 ел, №130; 30.10.2020 ел, №6; 06.12.2021 ел, №33; 16.05.2022 ел, №44; 18.07.2022 ел, №47; 27.10.2023 ел, №71; 05.06.2024 ел, №84; 21.04.2025 ел, №102 үзгәрешләре белән) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 "21 нче маддәнең 3 нче пунктының икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре ягыннан» дигән сүзләрдән соң «(муниципаль партнер түләве, капиталь грант күләме)» дигән сүзләр өстәргә;

1.2. "21 нче статья, 3 нче пункт, дүртенче абзацтагы «Бу чикләү таралмый» дигән сүзләрне «Бу пунктның икенче һәм өченче абзацларындагы чикләүләр таралмый» дигән сүзләр белән алыштырырга."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Россия Федерациясенең Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Хөснетдинов